**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлегенең Петровский Завод авылы торак
пунктында 2025 елда үзара салым кертү турында

**2024 елның 22 ноябрь** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең Петровский Завод авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге Петровский Завод авылы территориясендә, I нче группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкән кешеләр, көндезге бүлекләрдә укучы студентлар, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучылардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (Петровский Завод торак пунктында урам тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау (лампалар, таймерлар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру):

- Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Петровский Завод торак пунктында юлларны кардан чистарту (килешү буенча машина йөртүченең эшләренә һәм хезмәтләренә түләү), (Петровский Завод торак пунктынын Арьяк һәм Таулы урамнары юлын ремонтлау (таш белән капланган чокырлы ремонт, вак таш сатып алу, ташу, салу, килешү буенча хезмәтләргә түләү), Декабристлар урамында асфальт түшәлгән юлда чокырлар ремонтлау (асфальт валчыкларын ташу һәм салу, махсус техниканы арендалау, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, грейдерлау);

- Петровский Завод торак пунктында традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (территорияне чабу һәм коры агачларны кисү, триммер өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр һәм чыгым материаллары сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү; зират территориясен саклау өчен материаллар сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү; зиратка кадәр керү юлын төзү - вак таш сатып алу, ташу, салу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);

- Торак пункт территориясен төзекләндерү (Петровский Завод торак пункт территориясендэ улэн чабу, корыган агачларны кисү (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү); триммерлар өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу; тракторны тоту (Беларус МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьлар, чыгым материаллары сатып алу, килешу буенча хезмәтләр өчен түләү, территорияне чабу өчен триммерлар сатып алу;
- Петровский Завод торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү краннары сатып алу, урнаштыру һәм килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, янгын сүндерү җиһсәләре, янгын сүндерү бочка арбасы өчен тәгәрмәчләр сатып алу)
3. Әлеге карарны Петровский Завод авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар жыенында рәислек итүче Р.Р.Нуртдинов